ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы территориясендә аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) (алга таба – региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге)**

1. Региональ дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) предметы юридик затлар, аларның җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлары, индивидуаль эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан түбәндәге мәҗбүри таләпләрнең үтәлешеннән гыйбарәт:

1) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан аттракционнарның техник торышына һәм аларны эксплуатацияләүгә карата билгеләнгән таләпләрнең;

2) «Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында» Евразия икътисадый берлеге техник регламенты хакында» 2016 елның 18 октябрендәге 114 номерлы Евразия икътисадый комиссиясе берлеге карары белән кабул ителгән

«Аттракционнарның куркынычсызлыгы турында» Евразия икътисадый берлеге техник регламентында аттракционнарның куркынычсызлыгына карата билгеләнгән таләпләрнең.

2. Региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә таянып гамәлгә ашырыла.

4 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 23 декабрь
№ 95-ТРЗ